**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 март № 148

г. Казань

Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү һәм Россия Федерациясенең төбәк маршрут челтәрен формалаштыру турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1242 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1.Теркәлгән Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгын Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Бу карарның көче 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

Россия Федерациясе
территориясендә һава транспорты
белән төбәк эчендә пассажирлар
йөртүне гамәлгә ашыру өчен
Татарстан Республикасы
бюджетыннан һава транспорты
оешмаларына субсидияләр бирү
тәртибенә кушымта

**2016 елга Россия Федерациясе территориясендә гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртү маршрутлары исемлеге**

| Т/с | Һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртү маршрутлары | | Атнага парлы рейслар ешлыгы | Елга парлы рейслар саны | Махсус тарифның чик зурлыгы, сум | Бер парлы рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан авиапассажирлар йөртүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | шәһәр | шәһәр | | | | |
| 1 | Казан | Краснодар | 2 | 105 | 12 893 | 366125 |
| 2 | Казан | Нижневартовск | 2 | 104 | 12 893 | 366125 |
| 3 | Бөгелмә | Сочи | 2 | 82 | 12 893 | 366125 |
| 4 | Бөгелмә | Санкт-Петербург | 2 | 108 | 12 893 | 366125 |
| 5 | Бөгелмә | Нижневартовск | 2 | 105 | 12 893 | 366125 |
| 6 | Бөгелмә | Сургут | 2 | 82 | 12 893 | 366125 |

_______________________________

F:\KARAR\2016\148-1.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 17 март, 148 нче
карары белән расланды

**Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан аэропортлардан экономияле класстагы салоннарда һава судносы тарафыннан субсидияләнә торган маршрутлар буенча әлеге Тәртипкә кушымтадагы исемлек нигезендә (алга таба – субсидияләр) Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына (алга таба – авиапассажирлар йөртүчеләр) субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясенең һава законнарында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү һәм Россия Федерациясенең төбәк маршрут челтәрен формалаштыру турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1242 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү һәм Россия Федерациясенең төбәк маршрут челтәрен формалаштыру кагыйдәләрендә кулланыла торган мәгънәдә кулланыла.

3. Авиапассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Вәкаләтле орган) каралган ассигнованиеләр һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.

4. Субсидия алу хокукына авиапассажирлар йөртүчеләр – әлеге Тәртипкә кушымтадагы исемлек нигезендә Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы һәм Федераль һава транспорты федераль агентлыгы белән Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү һәм Россия Федерациясенең төбәк маршрут челтәрен формалаштыру турында шартнамә төзегән юридик затлар, аларның оештыру-хокук рәвешенә бәйсез рәвештә, ия була.

5. Субсидия бирү өчен Вәкаләтле орган һәм авиапассажирлар йөртүчеләр арасында Вәкаләтле орган раслаган форма буенча төзелгән субсидия бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) нигез булып тора.

Шартнамәдә субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе, субсидияләр күчерү вакытлары, авиапассажирлар йөртүченең фактта башкарган рейслары саны һәм йөртелгән пассажирлары күләме, факттагы пассажирлар

әйләнеше, кулланыла торган тарифлар авиапассажирлар йөртүчегә бирелергә тиешле субсидияләр турында хисап бирү формасы һәм ешлыгы, авиапассажирлар йөртүченең бу Тәртиптә һәм шартнамәдә билгеләнгән шартларны үтәвенә Вәкаләтле органның тикшерүләр үткәрү хокукы, субсидияләр алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык иптәшлекләреннән һәм устав (тупланган) капиталларында ачык-хокукый берәмлекләр катнашу юлы белән җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (тупланган) капиталларында мондый иптәшлекләр һәм җәмгыятьләр катнашкан коммерциягә караган оешмалардан тыш) аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә Вәкаләтле органның һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органының тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга субсидияләр алучының ризалыгы, шулай ук бу Тәртиптә һәм шартнамәдә билгеләнгән шартларны бозу факты ачыкланган очракта шартнамәне бозу тәртибе, авиапассажирлар йөртүче субсидия бирү шартларын бозган очракта субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе, субсидия бирү турында шартнамәләрдә каралган очракларда субсидияләрнең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешләрен субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару тәртибе күздә тотыла.

6. Субсидия алу өчен авиапассажирлар йөртүче ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органга гамәлдә башкарылган рейслар саны, гамәлдә йөртелгән пассажирлар саны, гамәлдәге пассажирлар әйләнеше, кулланыла торган тарифлар, авиапассажирлар йөртүчегә бирелергә тиешле субсидия турында хисап (алга таба – хисап) тапшыра.

Авиапассажирлар йөртүче хисаптагы мәгълүматларның дөреслеге өчен җавап бирә.

Субсидияләр ай саен бирелә һәм хисап аенда башкарылган рейслар саны белән әлеге Тәртипкә кушымтада каралган бер парлы рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидия күләме тапкырчыгышы буларак хисаплап чыгарыла.

Агымдагы елның декабре өчен субсидия агымдагы елның 20 декабреннән дә соңга калмыйча бирелә һәм бер юнәлештәге һәр маршрут буенча рейсларның пландагы саны белән бер рейска бирелә торган субсидия күләме тапкырчыгышы буларак хисаплап чыгарыла.

Агымдагы елның декабренә бирелгән субсидия күләме белән хисапта күрсәтелгән һәм декабрьдә гамәлдә башкарылган рейслар саны нигезендә исәпләнгән субсидия күләме арасындагы аерма хисап елыннан соң килә торган айның 31 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш.

7. Вәкаләтле орган хисапны алган көннән соң 5 көн эчендә аларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү яисә андагы мәгълүматларны тәгаенләргә кирәк булу турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар хакында авиапассажирлар йөртүчегә хәбәр бирә.

8. Хисаптагы мәгълүматларны тәгаенләргә кирәк булу турында хәбәрнамәдә Вәкаләтле орган тиешле карар кабул итү сәбәпләрен күрсәтә.

9. Авиапассажирлар йөртүче тәгаенләнгән мәгълүматлар белән хисапны бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Вәкаләтле органнан алган көннән

соң өч көн эчендә кертә.

10. Вәкаләтле орган җитешми торган тәгаенләнгән мәгълүматлары белән хисап кергән көннән соң ике көн эчендә субсидия бирү турында яисә бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

11. Авиапассажирлар йөртүчегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

а) бу Тәртипнең 6 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән вакытларда хисапны һәм (яки) тәгаенләнгән мәгълүматларны кертмәү;

б) шартнамәдә билгеләнгән таләпләрне бозу.

12. Вәкаләтле орган хисап аеннан соң килүче айның 25 еннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына субсидия бирүгә бюджет ассигнованияләренең гамәлдәге чыгымнары турында хисап кертә.

13. Субсидияне күчерү субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган хисап исәбенә шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

14. Авиапассажирлар йөртүче субсидияләр бирү шартларын һәм бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне бозган очракта, бирелгән субсидияләр Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләр алучылар субсидияне кире кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле орган бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт чыккан көннән соң эш көннәрендә исәплән торган җиде көн эчендә әлеге акчаны законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

15. Субсидияләрнең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше шартнамәдә каралган очракларда хисап елыннан соң килүче айның 31 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы субсидияләрне кире кайтару вакытын бозганда Вәкаләтле орган бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

16. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Рспубликасы Финанс министрлыгы субсидия алучыга субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

17. Бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Вәкаләтле орган гамәлгә ашыра.

---